Проект

Өркеш авыл җирлеге Советы

Карар

2022 елның 8 августы № 18

Өркеш авыл җирлеге Советының аерым карарларын гамәлдән чыгару турында

Өркеш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Өркеш авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

«Кукмара муниципаль районының Яниле авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 декабрендәге 33 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2018 елның 22 июнь 10 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган ТР Кукмара муниципаль районы Өркешавыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару, ташу һәм урнаштыру Тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2021 елның 23 ноябрендәге 25 номерлы карары;

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Ә.Ш.Әгъләмова